| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**27.12.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3380** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 19 декабрендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә,Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составын яңа редакциядә, әлеге карарга кушымта нигезендә, расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 06 октябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составына үзгәрешләр ккертү турында » 2247номерлы карарының 1 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев

Кушымта
Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитеты
карарына
27.12.2021ел, №3380

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| № т/б | ФИАт.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Ганиев Ильяс Рәсим улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе-**комиссия Рәисе** |
| **Комиссия әгъзалары:** | | |
| 2 | Хәбибуллин Зөлфәт Флүн улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| 3 | Хәббихуҗин Ирек Хикмәтулла улы | «Төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары-**комиссия секретаре** |
| 4 | Бауэр Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы; Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм үсеш бүлеге начальнигы |
| 5 | Содомова Юлия Александровна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге начальнигы |